Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2010 елның 31 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 25 июнь), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" Татарстан Республикасы Законына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең көнчыгыш өлеше керә, аның чиге шәһәрнең Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге уза торган төньяк чигендә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып К.Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр бара, шуннан соң сулга борыла һәм Иж-Бубый авыл җирлеге белән "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнчыгышка таба Татарстан Республикасы административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр үтә, аннары төньяк юнәлештә Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге буйлап К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан башлангыч ноктага кадәр бара.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Азево, Бима, Девәтернә, Исәнбай, Кадыбаш, Кичкетаң, Красный Бор, Күләгәш, Салагыш, Иске Эсләк, Иске Чекалда һәм Тәбәрле авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең көнбатыш өлеше керә, аның чиге шәһәрнең Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге уза торган төньяк чигендә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып К.Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлына кадәр уза, аннары шул ук юнәлештә Әгерҗе – Иж-Бубый автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр бара, шуннан соң уңга борыла һәм Иж-Бубый авыл җирлеге белән "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге буйлап көнбатышка таба Татарстан Республикасының административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары Татарстан Республикасының Удмурт Республикасы белән административ чиге буйлап төньяк юнәлештә К.Маркс урамы һәм Әгерҗе – Кече Пурга автомобиль юлы күчәр сызыклары киселешендә урнашкан башлангыч ноктага кадәр бара.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре керә: Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый, Кадрәк, Кырынды, Кодаш, Көчек, Яңа Бәзәкә, Сарсак-Умга, Тирсә һәм Шаршады авыл җирлекләре.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 17 июле
№ 66-ТРЗ